Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

# КАРАР

14 март, 2025 ел

№4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карары проектын хупларга (1 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы Кукмара шәһәре Советы карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында» Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

Фәттахов Ф.М. –комиссия рәисе;

Сафин И.И. – комиссия әгъзасы;

Шакирова Н.Н. –комиссия әгъзасы.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 07.04.2025.

5.2. Гавами тыңлауларны үткәрү вакыты – 17.00 сәгать.

5.3. Үткәрү урыны – Зур Сәрдек авыл мәдәният йорты бинасы, адресы: ТР, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Үзәк ур., 114 й.

Эшче төркемгә, ачык тыңлауларда кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы утырышында каларга кертергә.

**7.** Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatar.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы: ОГРН 1021607753232 ИНН 1623001727 Ф.М.Фәттахов

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2025 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына 1 нче кушымта

ПРОЕКТ

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

КАРАР

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге, кыскартылган атамасы – Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге (текстта алга таба – җирлек).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авылы территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы — Ф.М.Фәттахов

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2025 елның 14 мартындагы 4 номерлы карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карары проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Зур Сәрдек авыл җирлеге Советына кертелә адресы: ТР, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Үзәк ур., 141 й., яисә факс белән (84364) 24-5-36 кушымта итеп бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма формада:

| т/б № | Статья, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А, адресы, телефоны, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр карар игълан ителгән көннән бер ай эчендә кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша: ТР, Зур Сәрдек ав., Үзәк ур., 141 йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «гавами тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук факс буенча (84364) 24-5-36 тапшырыла.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8 сәгать 00 минуттан 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты Секретаре тарафыннан теркәлә һәм, карау өчен, Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгына тапшырыла.

Җирлек башлыгы Ф.М.Фәттахов

ОГРН 1021607753232 ИНН 1623001727